## Балтач гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Хәкимҗанова Алсу Илдар кызы рәхмәт хаты белән бүләкләнде

Бүген, ягъни 11нче февраль көнне, районыбызда узган зур чара - Алдынгылар җыенында мәгариф һәм фән өлкәсендәге күренекле казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен дәүләт бүләкләре алган мөгаллимнәребезне дә котладылар. Балтач гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Хәкимҗанова Алсу Илдар кызы Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтовның рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

